**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №190-35 « 20 » сентябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында»гы 2021 елның 29 ноябрендәге 58-12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмә хакында»гы 2021 елның 29 ноябрендәге 58-12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә (25.02.2022 №77-15, 25.10.2023 №154-22 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.3. бүлегенең 4.3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.3.5. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча Федераль законның 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы 90 статьясының 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.».

1.2. 4.5. бүлегенең 4.5.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.5.9. Рейд тикшерүе бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктларына һәм Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләренә яраклы рәвештә уздырылган очраклар керми.».

1.3. «4.7.4. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, моңа 2024 елның 08 августындагы 289 – ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше

һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин